ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУРБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«18» сентябрь 2019 ел.

**КАРАР**

№ 35

**Бөрбаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм аларны кулланy мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасының 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законы, 2004 елның 24 мартындагы «Татарстан Республикасында җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге Уставының 11 нче статьясы нигезендә , Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә 2019 елның 17 ноябрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын күрсәтергә:

"Сез 2020 елда референдумда тавыш бирү хокукына ия булган 18 яшькә җиткән Бөрбаш авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Бөрбаш авылында: торак пункт чикләрендә яр буенда агачлар, куаклар кисү һәм Кадермәт елгасы үзәнен төзекләндерү;

- Алан авылында: Советская-С.Садыйкова, Пионерская урамнарындагы юлларны өлешчә ремонтлау;

- Бөрбаш-Сәрдегәне авылында: балалар уен мәйданчыгы урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү, Г.Зарипов урамында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

**ӘЙЕ** **ЮК**

2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән һәм мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Балтач муниципаль районы
Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Галимуллин